**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

Кайбер затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе турында» 2015 елның 9 маендагы ПУ-431 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 28 июнендәге ПУ-553 номерлы һәм 2019 елның 13 апрелендәге ПУ-219 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында сәнәгать продукциясенең законсыз әйләнешенә каршы тору комиссиясе (алга таба – комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) комиссия составыннан А.В. Мәүликовны, Р.З. Тимерҗановны, Д.Г. Хәмитовны чыгарырга;

б) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Гәрәев Марат Мәсгут улын – Федераль таможня хезмәтенең Идел буе таможня идарәсе Татарстан таможнясы башлыгын;

Демидов Виктор Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны;

Хвостиков Игорь Владимировичны – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгын.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 02 октябрь
№ ПУ-648